КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 декабрь г.Казань № 1159

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган, акционерлык җәмгыятенең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында 50 проценттан күбрәк тәшкил иткән акционерлык җәмгыяте акцияләрен яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешен сату буенча конкурста җиңүчегә тавыш бирүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Татарстан

Республикасы дәүләт милкендә булган, акционерлык җәмгыятенең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында 50 проценттан күбрәк тәшкил иткән акционерлык җәмгыяте акцияләрен яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешен сату буенча конкурста җиңүчегә тавыш бирүне гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 декабрь, 1159 нчы
карары белән расланды

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»
2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы
19 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы
дәүләт милкендә булган, акционерлык җәмгыятенең һәм җаваплылыгы чикләнгән
җәмгыятьнең устав капиталында 50 проценттан күбрәк тәшкил иткән
акционерлык җәмгыяте акцияләрен яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең
устав капиталындагы өлешен сату буенча конкурста җиңүчегә
тавыш бирүне гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Бу Тәртип «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән һәм Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган, акционерлык җәмгыятенең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында 50 проценттан күбрәк тәшкил иткән акционерлык җәмгыяте акцияләрен яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешен сату буенча конкурста җиңүчегә тавыш бирүне гамәлгә ашыру процедурасын билгели.

2. Бу Тәртипнең гамәле конкурста катнашучыны конкурста җиңүче дип таныган көннән алып конкурста җиңүчегә конкурста үзе сатып алган җәмгыять акцияләренә (өлешенә) милек хокукы законнар белән билгеләнгән тәртиптә көчкә кергән көнгә кадәр кагыла.

3. Бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чорда җәмгыять идарәсе органы утырышы үткәрелгән очракта, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, җәмгыять идарәсе органыннан документлар кергән көннән 5 календарь көннән дә соңга калмыйча, конкурста җиңүчегә җәмгыять идарәсе органы утырышының көн тәртибен һәм аны үткәрүне әзерләүгә бәйле материалларны (белдерү, тавыш бирү бюллетеньнәре, башка материалларны) теркәп, җәмгыять идарәсе органы утырышын үткәрү турында хәбәрнамә җибәрә.

4. Җәмгыять идарәсе органы утырышының көн тәртибендә Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында каралган мәсьәләләр булганда, конкурста җиңүче, җәмгыять идарәсе органы утырышын үткәрү турында документлар кергән көннән 5 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге мәсьәләләр буенча тавыш бирүгә карата үзенең тәкъдимнәрен һәм конкурста җиңүченең утырышта катнашуына бәйле документларны кертә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, җәмгыять идарәсе органы утырышын үткәрү датасына кадәр 5 календарь көннән дә соңга калмыйча, конкурста җиңүчегә язма позиция, шулай ук законнар белән билгеләнгән очракларда ышанычнамә җибәрә.

6. Конкурста җиңүче бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чорда Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча җәмгыять акцияләре (өлеше) буенча җәмгыять идарәсе органнарында әлеге мәсьәләләр буенча мондый тавыш бирү вариантларының берсе күрсәтелгән язма позиция нигезендә һәм законнар белән билгеләнгән очракларда мондый тавыш бирүдә катнашу өчен конкурста җиңүчегә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан бирелә торган ышанычнамә нигезендә тавыш бирүне гамәлгә ашыра.

7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының язма позициясе Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында каралган мәсьәләләр буенча җәмгыять идарәсе органнарында акцияләр (өлеш) буенча тавыш биргәндә конкурста җиңүче тарафыннан үтәлү өчен мәҗбүри була.

8. Әгәр конкурста җиңүчегә җәмгыять идарәсе органы утырышын үткәрү көненә кадәр Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының язма позициясе килмәгән булса, конкурста җиңүче утырышта Федераль законның 20 статьясындагы 19 пунктында каралган мәсьәләләр буенча җәмгыять акцияләре (өлеше) буенча тавыш бирүдә катнашмый.

9. Конкурста җиңүче җәмгыять идарәсе органы утырышы беркетмәсе күчермәсен утырыш үткәрелгәннән соң 5 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрә.

___________________________